МӘҢГЕЛЕККӘ ЮЛ ТОТУЧЫНЫҢ

# АХИРӘТ ПАСПОРТЫ

ХУЗУР
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ

www.darul-kutub.com

| | |
|---|---|
| ИСЕМЕ: | АБДУЛЛАҺ |
| АТАСЫНЫҢ ИСЕМЕ: | АДӘМ |
| АНАСЫНЫҢ ИСЕМЕ: | ҺАВА |
| ТОРУ УРЫНЫ: | ҖИР |
| ДИНЕ: | ИСЛАМ |
| КИТҮ ЮНӘЛЕШЕ: | АХИРӘТ |

Мәңгелеккә юл тотучының **АХИРӘТ ПАСПОРТЫ.** – Казан: Хузур-Спокойствие, 2014. – 88 бит.

**Бик мөһим бер искәртү!** «Мәңгелеккә юл тотучының АХИРӘТ ПАСПОРТЫ» исемле бу рисалә (брошюра) – һәр кеше, бигрәк тә һәр мөселман өчен иң соң дәрәҗәдә кирәкле темаларны үз эченә алган һәм шунлыктан, аны укыганда өстән-өстән генә күз йөртеп түгел, ә бәлки дикъкать белән бик җентекләп уку сорала. Күзаллау һәм аң-фикер механизмнарын хәрәкәткә китереп, күңелең һәм рухың белән аның тәэсирен мөмкин булган кадәр тирәнтен тоеп уку өчен тырышырга кирәк.

www.darul-kutub.com

# ӘЙ, КЕШЕ!

Әй, кеше, син бер юлчы бит,
бармы яныңда ризык?
Ризыксыз юлга чыгучы үзенә итәр язык!

Бу юл озын һәм нәзек, син аңа хәзермесең?
Эшләгән эшләреңне һәр мизгел күздән кичер.

Гөнаһ йөгеңне кимет син,
үкенерсең соңыннан.
Син йокларсың,
әмма ләкин йокламас бер дә дошман!

Үлем көн тәртибендә, беркем кире кагалмас.
Һәр көн сине илтә алыр бер җил теге тарафка...

Тормыш, үлем һәм зират;
мәхшәр, мизан һәм сират.
Әҗәл дигән почтальон шул кадәр
якынлашкан.

Әй кеше, уйлан, әзерлә «паспортыңны»!
Сине көтәдер һәр мизгел соңсыз ахирәт
йорты.

www.darul-kutub.com

# ТӘКЪДИМ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

Тормышны һәм үлемне бер имтихан чарасы итеп бар кылган Раббыбызга чиксез мактаулар булсын! «Нәсыйхәт  буларак үлем җитәрлек», – дип боерган барлык дөньяларның Хуҗасына, Аның якыннарына һәм әсхабына бик күп сәламнәр булсын!

*Ахирәткә юл тоткан кадерле укучы кардәшем!*

Билгеле булганча, без тугач башланып, үлгәндә тәмамланган бу чикле бер галәмдә без кунак кына. Кайчан киләсе билгеле булмаган, ләкин һәр минутта килүе мөмкин булган бер чынбарлык каршыбызда. Ул да булса – үлемдер...

Шушы фани дөньяда бер илдән икенче илгә киткәндә бездән паспорт, виза шикелле күп нәрсәләр сорыйлар. Бу документлар булмаса, чиктән узып булмаганын, ул очракта зур кыенлыклар кичерәчәген һәркайсыбыз беләдер.

Без мөэмин буларак, «үлем чынбарлыгына» һәм кичектергесез булачак ахирәт көненә һич тә икеләнмичә ышанабыз.

www.darul-kutub.com

Хәл шундый була торып та, бик күбебезнең «үлем чынбарлыгына» каршы җитди хәзерлек алып бармавыбыз читен сорау буларак каршыбызда торачак.

Һәр көндә, һәр сәгатьтә, хәтта һәр мизгелдә тирә-якта булып торган үлем очракларының безгә булган тәэсире, ни кызганыч, бик озакка калмыйча, тиз арада юкка чыга.

Югыйсә, үлемне хәтерләүнең һәм аңа хәзерлекле булуның никадәр әһәмиятле икәнлеген беркем инкарь итә алмас.

Югарыда әйтеп үтелгәнчә, бер илдән икенче илгә киткән юлчының паспорт, виза һәм башка шундый документлары булуның әһәмиятен һәркем яхшы аңлый.

Шулай булгач, бу фани дөнья иленнән мәңгелек ахирәт иленә юлга чыккан вакытта, безгә кирәк булачак паспортыбыз һәм визабыз хәзерме соң әле безнең?

Әлеге һәм башка бик күп сорауларга җаваплар тәшкил иткән, тирән эчтәлеккә һәм бик зур әһәмияткә ия булган бу рисалә белән сезне ялгыз калдырам, кулыгыздан һичбер вакыт җибәрергә теләмәссез сез аны.

www.darul-kutub.com

Рисаләнең файдасын арттыру максатыннан, үзебез мөһим дип санаган ике эшебезне өстәмә итеп керттек. Аларның берсе «Дини васыятьнамә», икенчесе «Ахирәт һава юллары» дип атала.

Бу әһәмиятле әсәрне хәзерләгән, тәрҗемә иткән, нәшер итүдә ярдәмче булган, укыган һәм укытылуына юл ачкан һәркемгә илаһи рәхмәттән өлеш чыгарсын иде дип, бөек Раббыбыздан үтенеп сорыйбыз.

* * *

www.darul-kutub.com

# АХИРӘТ ПАСПОРТЫБЫЗ ХӘЗЕРМЕ?

Аллаһыга һәм ахирәт көненә инанган чын мөэмин үлемгә һәрвакыт хәзер булырга тиеш. Чөнки үлемнең кайчан киләчәге турында беркемгә дә хәбәр бирелмәгән, аның көне һәм сәгате алдан билгеле булмаган.

Нигездә, инанган кеше үлемнең һәр мизгелдә килергә мөмкин икәнлеген аңлап белгәне өчен, үлемнән соңгы мәңгелек тормышка хәзерлекле хәлдә булырга тиеш.

Мөэмин кеше үлемне җәннәткә керер өчен бер күчеш буларак күрер һәм аны Бөек Аллаһының әмере итеп кабул итәр, соң дәрәҗә буйсынган хәлдә каршылар. Шуның өчен ул үзенең бар көче белән хәерле эшләр кылырга тырышып яшәр, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга омтылыр. Шуны да онытмаска кирәк: үлемгә хәзерлекле булган кешеләр үз гомерләренең ахырына кадәр «өмет белән курку» арасында яшәрләр.

Аллаһыга һәм ахирәт көненә инанган чын мөэмин, үлем хакыйкатенә иман иткәнгә күрә,

www.darulkutub.com

җәннәтне өмет итсә дә, икенче яктан үзен кимчелексез дип санамаганлыктан, җәһәннәмнән дә куркыр. Коръән-и Кәримдә мөэминнәрнең начар хисаптан куркулары, үз-үзләрен матур итеп тотулары һәм алар ирешәчәк яхшы нәтиҗә шул рәвештә белдертелгән:

**«Раббылары ризалыгын алырга теләп алар сабырлык күрсәтәләр, намазларын кылалар. Без биргән ризыктан инфакъ итәләр, яшерен һәм ачыктан сакланалар, һәм игелек белән начарлыктан арыналар. Ахирәтнең гүзәл йорты алар өчен әзердер»[1].**

Коръән аятьләрендә тасвирланган куркыныч җәһәннәм мохитен һәм аның газапларын мөэмин һәрвакыт исендә тотар һәм Аллаһыга юнәлер. Һәр мизгелдә үзенең үлем фәрештәләре белән очрашуы мөмкин икәнлеген һич онытмыйча хәрәкәт итәр. Биргән карарларында, эшләгән гамәлләрендә, сөйләгән сүзләрендә гел җәннәткә ирешүне һәм җәһәннәм газабыннан котылуны күз алдында тотар.

Башкарган һәр хәрәкәтнең һәм әйткән һәрбер сүзнең җәннәткә яки җәһәннәмгә якынлаштырачагын яхшы аңлаган мөэмин, Аллаһының риза-

1 «Рәгыд» сүрәсе, 13:22.

www.darulkutub.com

лыгына туры килмәгән сүзләрдән һәм эшләрдән һәрвакыт тыелыр. Үзенең һәр мизгелдә үлем белән очрашачагын белеп, һәр мөмкинлектән тагы да күп әҗер-савап казана алыр өчен акылын, аң-фикерен ачык тотар; җәннәттә кавышуның тойгы-кичерешләре белән җәһәннәмнән ерак булуга ныклы өметләр белән яшәр.

Чын мөэмин булган кеше гомере буена үзенә һәр минутта үлем фәрештәсе килү уе белән хәрәкәт итәр һәм беркемне дә рәнҗетмәс, хаксызлык эшләмәс өчен бар көчен куяр***. Гыйбадәтләрендә ваемсызлык күрсәтмәс, һәрвакыт Раббысының яхшы колы булу гайрәтендә булыр.***

Мөэмин гүя үлем хәлен кичергән сыман, ахирәт галәменә инде китеп, җәннәтнең гүзәллеген һәм җәһәннәмнең куркынычлыгын күреп, бу дөньяга кире кайткан сыман аек акыл һәм иман белән ахирәткә хәзерләнер. Һәр очракта намусы кушканча эш итәр. Чөнки шуны бик яхшы белә: ул күрсәткән иң кечкенә тискәрелек яки вөҗдансызлык ул көнне аның үзе өчен бик тә зур үкенечкә сәбәп булырга мөмкин.

www.darulkutub.com

Менә шулай итеп, үлемгә һәр сәгатьтә хәзерлекле булыр өчен Коръәннең шул аятен һич исеннән чыгармас:

**«Аллаһыдан куркыгыз сез көчегез җиткән кадәр...»**[2]

Мөэмин һичбер вакытта шул илаһи хәбәрне акылыннан чыгармас:

**Әйт: «Сез үлемнән качсагыз да, ул сезне тотып алачак. Ахырда, күренгәнне һәм яшеренне белгән Аллаһ хозурына китереләчәксез. Аллаһ ни кылганыгыз турында сезгә хәбәр бирәчәк»**[3]**.**

Үлем турында уйлануның файдаларын пәйгамбәребез, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, үзенең хәдис-шәрифләрендә шул рәвешле ачыклаган:

**«Үлемне ешрак искә алыгыз, чөнки ул (сезне) гөнаһ эшләүдән тыеп калыр һәм дөньядан ераклаштырыр».**

**«Үлемне иң күп зикер итүчеләр һәм үзләренә килгәнчегә кадәр аңа иң яхшы хәзерләнүчеләр – алар кешеләрнең иң зирәкләре»**[4]**.**

2 «Тәгабүн» сүрәсе, 64:16.
3 «Җомга» сүрәсе, 62:8.
4 Ибн Мажәһ, «Зүһд», 31

Әйе... Үлемгә һәрвакыт хәзер була алыр өчен мөэмин гомере буенча ***«курку*** белән ***өмет»*** арасында яшәр. Хисап көненнән куркып, җәннәткә яки җәһәннәмгә керүне көткән кешеләрнең рухи хәлләрен һич тә хәтереннән чыгармас.

***Ахирәт паспортлары*** *хәзер булганнарның рухи хәлләре шундый булырга тиеш...*

* * *

www.darul-kutub.com

# ҮЛЕМ – ДӨНЬЯДАН КИРЕ КАЙТЫШ ЧАРАСЫ

*Кисәту!*

Юлчыларыбыз калачак җирләр, кунакханәләрдә аларга тәкъдим ителәчәк шартлар, аларның бу дөньяда вакытта кылган гамәлләренә күрә билгеләнер.

Өстә бүлмәләр булган, астан елгалар аккан җәннәтләрдә алар өчен хәзерләнгән матур торак җирләре.

Тәме һич тә үзгәрмәс һәм бозылмас сулары, җәннәтнең шәраблары, саф баллар ага торган җәннәтнең елгалары.

Эченә тәмле исле зәгъфран тутырылган якут, энҗе, мәрҗаннан эшләнелгән түшәкләр.

Үзләре теләгән җимешләр, җаннары теләгән кош итләре.

Ә андагы киемнәр, барысы да иң яхшы тукымалардан тегелгәннәр, көмеш һәм энҗе белән бизәлгәннәр. Бик тә күркәм булыр алар һәм һәрвакыт кулланылышка хәзерләр.

www.darul-kutub.com

Бу шартларга ирешергә теләүчеләр астарак күрсәтелгән тәгълиматларны сүзгә-сүз, бик җентекләп башкарырга һәм аларга бирелгән бланк кәгазьләрен тәгәл итеп тутырып, бу эш белән шөгыльләнүче фәрештәләргә тапшырырга тиешләр. Мондагы «паспорт контролендә» түбәндәге сораулар күз алдында тотылачак:

1. Раббысының яхшы колы идеме ул?

2. Үзенең кылган гамәлләрен яхшы хәтерлиме?

3. Үзен күрмәгән килеш тә, Раббысыннан тиешле дәрәҗәдә курка идеме? Аңа хөрмәт белән карады һәм буйсындымы?

4. Бирегә Кальби-Сәлим (керсез күңеле) белән килдеме?

Бу паспортта язылган күрсәтмәләрнең бермә-бер үтәлүе соралыр.

* * *

www.darul-kutub.com

# КЕРЕШ СҮЗЕ

Безне башка җанияләреннән аермалы буларак акыл иясе итеп яралткан һәм безгә ихтыяр көче биргән Аллаһы Тәгаләне кимчелекле сыйфатлардан азат дип беләбез.

Иң элек үзебездән шуларны сорыйк әле:

Бу дөньяга килүебезнең, яшәү һәм китүебезнең максатын беләбезме?

Мәңге калачак җиребез булган ахирәткә без ни дәрәҗәдә хәзерләндек?

Анда үзебез өчен алдан ниләр күндердек?

Гамәл дәфтәрләребездә ниләр язып куелган?

Без төшереп куелачак ул караңгы чокырга, озын ахирәт юлына менә шушы мизгелдә әзерме соң инде без?

Әгәр без дөньяның вакытлыча булуын истә тотып, яшәешебезгә һәм үлемгә җитди карамасак, ахирәт тормышына әһәмият бирмәсәк, башка яратылганнардан нинди аермабыз булыр? Ул тәкъдирдә безнең өчен котылу, яхшылык, уңышка ирешү, бәхетле һәм мул тормыш, ике җиһан сәгадәте мөмкин булырмы?

Шуны да онытырга ярамый: югарыда аңлатылганнар бары тик тәкъва белән Аллаһы Тәгаләгә юнәлгәндә, Ул тыйганнардан тыелып яшәгәндә генә мөмкин булачак.

www.darulkutub.com

*Кадерле укучы туганым!*

Бу китапчыкта тормышның соңгы сәяхәте, мәҗбүри тукталышлардан булган кабер хәяте, Мүнкәр белән Нәкирнең сораулары, яңадан терелү, кыямәт, җәннәт яки җәһәннәм кебек һәр кешенең башыннан үтәчәк эшләрне баштан ук хәтерләтергә теләдек.

Аллаһны искә алганда, күңелләребезне курку биләсен иде, киләчәк дәһшәтле көндә йөзләребезне ак итсен. Ә бит ул көнне саф күңел белән килүчеләргә генә котылу булачак; ахыр чиктә берни дә: мал-мөлкәт тә, балалар да файда бирмәячәк, бар серләр ачылачак, кабердәгеләр нык курку һәм борчу белән кубарылып чыгачак, яхшылык белән яманлык аерылачак.

Шулай ук Раббыбыздан шуларны үтенәбез һәм ялварып сорыйбыз: безне Үзенә буйсынучан итә күрсен, гел һидаять юлында булганнардан итеп кылсын һәм безгә ярдәм итсен иде, чөнки барлык көч-куәт бары тик Анда гына.

Һәм безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа, салләллаһу галәйһи үә сәлләмгә, аның гаиләсенә һәм әсхабына чиксез сәламнәр булсын!

* * *

# БАГАЖ

*Мосафир туганым минем!*

Сөйлә зинһар, ахирәткә син ниләр хәзерләдең?

Тәкъвалык (аңлы рәвештә).

Курку (Аллаһыны хөрмәт итү һәм олылау).

Нинди кием хәзерләдең син Аллаһ Тәгалә каршында? Аннан оялу, яисә шәһүәт һәм Аллаһыдан ераклашу киемнә-ренме?

– Караңгы һәм тар булган кабер хәяте өчен ризык хәзерләдеңме?

– Анда синең япа-ялгыз, кайгылы һәм онытылган хәлдә калуың бар.

– Андагы азыгың турында алдан уйлап куйдыңмы?

Кабернең караңгылыгына һәм тарлыгына түзә алыр өчен нәфесеңне күнектерлеңме?

Бу озак һәм бик ерак күчешкә инде син хәзерләнденме бераз?

Иңбашларына күтәреп кабергә илткәндә, син ни диячәксең?

Үзеңнең якыннарыңа, җеназаңа килгәннәргә син ниләр әйтәчәксең?

«Каһәр төшсен сезгә, мине кая илтәсез?» – диярсеңме, әллә юкса: «Мине тизрәк илтегез!» – диярсеңме аларга?

www.darul-kutub.com

*Әй, ахирәткә юл тоткан кардәшем!*

Әгәр тәкъва киеменә төренгәнсең икән, димәк син котылдың. Гыйсъян күлмәген кисәң – яндың. Шайтан юлыннан йөрсәң, мөнафикъләрдан булырсың. Аллаһы юлыннан китсәң – әүлиядән, Аллаһының дусларыннан саналырсың.

«Дөреслектә, Аллаһы юлындагылар курыкмаслар һәм хәсрәттә калмаслар»[5].

Сәяхәтегез өчен бирелгән әлеге сумканы югарыда аңлатып үткәнчә тутырсагыз, алга таба әйтеләчәк җирләргә китәрсез. Моның өчен «Кая кайтабыз?» дигән бүлекне игътибар белән укып, асылына төшенергә тырышыгыз!

* * *

5 «Юныс» сүрәсе, 10:62.

www.darulkutub.com

# КАЯ КАЙТАБЫЗ?

Хәзер инде тирәннән уйлап, хозур һәм хушлык эчендә үз-үзеңә сорау биреп кара:

Аталарым, аналарым, бабайларым, әбиләрем, мал-милке күп булып та, дөньяда бер-берсеннән уздырырга тырышканнарның ничек икән хәлләре? Әгәр яхшы төшенсәң, җавабын табачаксың. Малларының һәм туфракның астында ята алар...

*Шушы хәлдә, туганым!*

Китабыңда, гамәл дәфтәреңдә кимчелекләр, җитешсезлекләр бармы икән? Әллә инде син аларны оныттың һәм юкка санадың?

Бервакыт, Ибраһим ибне Әдһәм хәзрәтләреннән берәү: «Үлгән кешенең иманы кайда?»– дип сораган. Ул учына туфрак алып: «Аның иманы монда!» – дип җавап кайтарган.

*Мөслимә апам минем!*

Көннәрдән бер көнне бер мөслимә хатын мәет юарга булышкан, мәрхүмәне җирләү өчен хәзерләгән иде. Шунда ул вафат булган

хатынның чәчләрендә төенчекләр оешканын күрә. «Аллаһы белер, бу мәрхүмә Раббысыннан бик ерак яшәгәндер», – дигән фикергә килә. Ә соңыннан үз-үзенә: «Кайчандыр бу хатын да яшь булган, үзен иркен тотып, чәчләрен таратып, «матурлыгымны һәркем күрсен» дип йөргәндер. Хәзер үзен күр инде! Туфрак белән тиңләшкән, инде хәзер Аллаһыга хисап бирәчәк».

Саф-чын тәүбәгә сарыл! Вакытың узганчы, Аллаһыга таба борыл!

**«Гомере буе яманлыклар кылып, якасыннан үлем килеп тоткач кына: «Тәүбә итәм!» – дигәннәргә һәм кяфер булып үлгәннәр өчен ярлыкау юк. Андыйлар өчен әче газап хәзерләнгән»[6].**

Инде вакыт җиткән икән, аннан һич тә качып котылу юк!

Алдагы бүлекләрне игътибар белән укы!

* * *

6 «Ниса» сүрәсе, 4:18.

www.darul-kutub.com

*Сәяхәт якынлашты!*

Син яхшы беләсең: бу дөнья бик кыскадыр, аны ничек озайта алырсың?

Син шулай ук беләсең: бу дөнья әһәмиятсез һәм кыйммәтсездер. Ничек итеп аңа хөрмәт күрсәтәчәксең?

Төн никадәр озын тоелса да, көн туугa мохтаҗ.

Гомере озын булса да, кеше кабергә мохтаҗ.

Бу дөньяда иң бөек хакыйкатьне эзлисеңме? Менә ул хакыйкать – үлем, Аллаһының әйтүенчә:

**«Көннәрдән бер көнне үлем иләслеге килер. Синең гомер буе качып йөргән нәрсәң, шул (әҗәл) булыр»[7].**

Авырган чакларыңда син табибка барасың, ач вакытта ризык кабасың, сусагач су аласың. Фәкать Аллаһының әмере булган үлемнән кай-да, ничек качарсың?

**«Җаныгыз бугаз төеренә кадәр менеп җиткәч: «Кем безне дәвалар, кем коткарыр?!» – дип кычкырырсыз. Шунда гына кеше җаннан аерылыр вакыт җиткәнен белер»[8].**

---

[7] «Каф» сүрәсе, 50:19.

[8] «Кыямәт» сүрәсе, 75:26-28.

www.darulkutub.com

Әйе, аңлаган һәр акылга, ишеткән һәр колакка игълан ителгән иң бөек хакыйкать шушы була инде. Бөтенләй юкка чыгу да, мәңгелек булып калу да – бары Аның кулында. Адәм затыннан булган һәркем очрашачак соңгы хакыйкать һәм барлыгының бер билгесе – ҮЛЕМ.

Фәкыйрь яки бай булсын, танылган яки гади кеше булсын, барысы да бертөрле ак кәфенгә төренеп китәчәк бу дөньядан. Әмма бу һичбер вакыт аның ахыры түгел. Яңадан терелүнең, Раббы каршына килүнең башлангычы – ул кабер.

*Юлчы кардәшем!*

Киләсе бүлектәге теманы яхшы укып, үзеңне ниләр көткәнен төшенерсең.

* * *

www.darul-kutub.com

# ИҢ ЗУР ИМТИХАН

*Сөекле туганым!*

Нәтиҗәсе я җәннәт, я җәһәннәм булган бу бөек сынауның сорауларын исеңә төшер! Ул сораулар түбәндәгеләр:

**Кабердә:**

Раббың кем?

Динең нинди?

Пәйгамбәрең кем?

Әхмәд ибне Хәнбәл риваять иткән хәдистә әйтелгәнчә, бу сораулар синнән дә соралачак.

Кыямәт көнне элеккеләрдән һәм соңгылардан: «Сез Аллаһыга ничек гыйбадәт иттегез? Пәйгамбәргә ни рәвешле иярдегез?» – дип соралачактыр.

**Ул көнне Аллаһ Тәгалә әйтер: «Уйлап чыгарган һәм Аллаһка тиң саналган уртакларыгыз кайда?»[9]**

**Ул көнне Ул аларга эндәшер: «Пәйгамбәрләремә ни дип җавап биргән идегез?» – дип сорар[10].**

[9] «Касас» сүрәсе,28:62.

[10] «Касас» сүрәсе,28:65.

www.darulkutub.com

Һәр кешедән ул көнне әлеге сораулар соралачак:

Гомерен ничек үткәрде?

Яшьлегендә ни эшләде? Тормышын нәрсәгә багышлады?

Мал-мөлкәткә ничек иреште һәм нәрсәгә сарыф итте?

Нинди яхшы яки яман гамәлләр башкарды?

Җәнабы Хак болай дип боерды:

**«Белмәгән нәрсәгә иярмә. Колагың, күзең һәм күңелең сине җавапка тартыр»[11].**

**«Валлаһи, дип әйтәмен ки, кылган гөнаһлары өчен Без аларны җавапка тартырбыз»[12].**

Әлеге сорауларга дөрес җавап бирү юлы ул дөрес иман, изге гамәл, тәкъва, саф-чын тәүбә белән тәүбә итү.

*Әй, ахирәт юлчысы!*

Югарыда китерелгән сорауларга җавабыңны хәзерләдеңме?

Хисапка тартылганчы үзеңнән хисап сорадыңмы?

[11] «Исра» сүрәсе, 17:36.

[12] «Хижр» сүрәсе, 15:92-93.

www.darul-kutub.com

Бу сорауларга җавап бирүне җиңеләйткән ризыгың яныңдамы?

Моннан соң сине ниләр көтә?

**Киләсе бүлекчәгә дикъкать ит!**

* * *

www.darul-kutub.com

# СЫЙРАТ

Сыйрат – ул җәһәннәм өстенә корылачак, һәр кеше үз гамәлләре нисбәтендә кичә алачак күпер. Хәдис-шәрифтә әйтелгәнчә, кайбер кешеләр яшен тизлегендә, кайберләре җил яки чабыш аты тизлегендә, башкалары акрынлап, кайберәүләр сөйрәлеп кичәчәк ул күпердән. Фәрештәләр:

«Аллаһым, боларны исән-имин кичер!» – дип дога кылачаклар, ләкин гамәлләре яхшы булмаганнар һәм кяферләр җәһәннәмгә төшәчәкләр. Бу сыйрат кылычтай үткен булыр. (Хәзерлексез килүчене кисеп кенә төшерер).

Сыйрат күпере җәһәннәмнең өстендәдер. Һәр кеше кебек без дә аннан кичәчәкбез, җәһәннәмне якыннан күрәчәкбез.

**«Анда керергә тиешле булмаган һичбер кеше арагызда юк. Бу – Аллаһның катгый карар иткән котылгысыз хөкемедер»[13].**

Бу аяти-кәримә иңдерелгәч, әсхабы-кирам кайгыга төште. Ә соңыннан, түбәндәге аять иңде:

---

[13] «Мәрьям» сүрәсе, 19:71.

www.darulkutub.com

**«Соңыннан Без Аллаһтан куркып, тәкъва булганнарны коткарырбыз. Залим булганнарны исә, тезләнгән килеш шунда калдырырбыз»[14].**

Пәйгамбәребез салләллаһу гәләйһи үә сәлләм: ***«Бәдердә һәм Худәйбиядә шәһид булганнар җәһәннәмгә кермәячәктер»,***– дигәннән соң, Хәфса радыйаллаһу гәнһә: *«Коръәндә Сездән җәһәннәмгә кермәгән юктыр диелмәгәнмени?»* – дип сорагач, ул икенче аяти-кәримәне укыды.

Җәһәннәм өстендә тозаклар бардыр. Тозаклардан бары тик Аллаһының нигъмәтенә шөкер иткәннәр генә котылыр. Кяферләрне исә җәһәннәм газабы көтәр.

*Әй, сөекле кардәшем!*

Син бу күчешне үтәр өчен үзеңә ниләр хәзерләдең?

Ул көнне сыйрат өстендәгеләрнең хәле белән кызыксынасың икән, киләсе этапка рәхим ит!

* * *

14 «Мәрьям» сүрәсе, 19:72.

www.darul-kutub.com

# Мөэминнәрнең сыйрат күперендәге хәле

Аллаһы Тәгалә әлеге аяти-кәримәсендә мөэминнәрнең сыйратны ничек кичәчәкләрен белдерә:

**«Кыямәт көнендә мөэмин ирләрне, мөэминә хатыннарны күрерсең. Аларның алдыннан да, уң ягыннан да нурлары яктыртып барыр. Бүген сезгә сөенче! Чишмәләре агып торган җәннәт бакчаларына керерсез. Сез анда мәңге калырсыз. Бу – бөек котылышның үзе булыр»[15].**

Аллаһы Тәгалә мөэминнәрнең хәлләрен безгә шул аяти-кәримә белән аңлата:

**«Әй, иман китергәннәр! Ихлас тәүбә итеп, Аллаһка кайтыгыз. Ихтимал, сезнең хаталарыгызны Аллаһ кичерер. Пәйгамбәрне һәм аның белән бергә иман китергәннәрне хур итмәс. Сезне чишмәләре агып ята торган җәннәтләренә кертер. Аларның алдыннан, уң якларыннан нурлары яктыртып барыр. Алар әйтер: «Әй Раббыбыз! Тулы ит нурыбызны, гафу кыл барыбызны. Һәрнәрсәгә дә Синең**

[15] «Хәдид» сүрәсе, 57:12.

www.darul-kutub.com

**кодрәтең җитү хактыр»**[16]**.**

Менә шулай, Аллаһы Тәгалә безгә мөэминнәрнең сыйраттагы хәлен аңлата. Ибне Маҗәһ риваять итүенчә һәм бу аяти-кәримәнең тәфсирендә (Ибне Кәсир) аңлатылганча, мөэминнәр үзләренең гамәлләренә күрә нурланачаклар. Кайберсенең нуры таулар кебек яки гәүдәсе кадәр, кайберсенең биленә тикле, кайберәүләрнең аягы яки тырнагы кадәр булачак. Һәм хәтта иң соңгысына да җәһәннәм: «Әй, мөэмин, тизрәк кич, синең нурың минем утымны сүндерә!» – дип тавыш бирәчәк.

Нурының таулар кадәр булуын һәм җәһәннәм өстеннән яшен кебек кичүне кемнәр генә теләмәс икән? Шул сәбәпле, сыйраттан тизрәк кичәр өчен күбрәк изге гамәл кылырга ашыгыйк**.**

*Әй, мөэмин кардәшем!*

Икейөзле монафикъларның андагы хәлләрен белергә телисеңме?

Алар да синең белән бергә киләчәкләр һәм аларның ничек итеп аерылачакларын алдагы бүлектән белерсең.

16 «Тәһрим» сүрәсе, 66:8.

www.darulkutub.com

## Монафикъларның сыйрат күперендәге хәлләре

«Ул көнне монафикъ ирләр белән монафикъ хатыннар иман китергәннәргә: «Көтеп торыгыз безне, бераз без дә яктылыгыгыздан файдаланыйк»**. Аларга: «Узганыгызга кайтып, яктылык эзләгез», – дип әйтерләр.** Ниһаять, алар арасына капкалы койма барлыкка килер. Ул койманың бер ягында сәгадәт, икенчесендә газап булыр».

Шул рәвешле, мөэминнәрнең нурларыннан, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән монафикъларның файдалануына киртә куелачак. Аларга нур таратылган бу дөньяга кире кайтып, нур эзләргә кушылыр, әмма бу мөмкин булмас. Араларына үтеп булмый торган бер экран эленер, бер тарафы рәхмәт булыр, икенчесе газаптыр. Нур шулай итеп бүленер, мөэмин белән монафикъның арасы аерылыр. «Безне көтеп торыгыз, без дә сезнең яктылыгыгыздан ичмасам бер нур алыйк, бу дөньяда чакта бергә идек» – дигәч, мөэминнәр монафикъларга: «Сез дә безнең нур алган дөньяга кире китеп, нур алып килегез», – диячәкләр. (Карагыз: «Хәдид» сүрәсе, 57:13.)

www.darulkutub.com

**«Бүген инде мөселманнардан да, инкарьчылардан да фида кабул ителмәс. Барасы җирегез – ут. Сезгә шул лаек. Коточкыч җир ул – барасы җирегез».**

Ягъни, дөнья кадәр алтын бирсәгез дә, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан котыла алмассыз.

*Әй, сөекле туганым!*

Ул көнне дөрестән дә мөэминнәр белән бергә булырга телисеңме? Әгәр дә шулай икән, бүгеннән үк хәзерлән!

Бөек күзәтүчеләрне күрергә һәм котылырга телисеңме? Киләсе бүлекне укы!

* * *

www.darul-kutub.com

# БӨЕК ТУПЛАНЫШ

*Әй, ахирәткә юлга чыккан туганым!*

Кешеләр кыямәт көнендә каберләреннән яланаяк һәм ялангач килеш, анадан тумыш хәлдә чыгачаклар. Хәзрәти Гайшәдән (радыйаллаһу гәнһә) риваять ителгән: «Инсаннар ул көнне элек яратылгандай, шәрә килеш хәшер ителерләр. Мин дә: *«Йә Рәсүлуллаһ, алар бер-берсенә начарлык эшләмәсләрме?»* – дидем.

Моның өстенә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләм: ***«Аларның авырлыктан бер-берсенә карарлык хәлләре юктыр»,*** – диде.

Алар бары тик үз хисаплары хакында гына уйлаячак, йөрәкләрен курку алачак.

Ул көнне барлык кешеләр өч төркемгә бүленер:

Бер өлеше бик тиз чапкан атлардай киләчәкләр. Болары мөэминнәрдер.

Башкалары бераз акрын, җәяү йөреп килерләр. Болар дөньяда вакытта яхшы гамәл аз кылганнар, ваемсызлык күрсәткәннәр.

Кайбер кешеләр исә, йөзтүбән капланган килеш, өстерәлеп килерләр. Бу ишеләрнең урыны җәһәннәм булачактыр.

www.darul-kutub.com

Кыямәт көне хакында Җәнабы Хак болай дигән:

**«Раббыңның нуры белән бөтен җир яктыртылыр, Китап китереп куелыр, һәм пәйгамбәрләр белән шәһидләр китерелер. Гаделсезлек күрмәсләр, аралары хаклык белән гадел хөкем ителер»[17].**

**«Кыямәт көнендә Без гаделлек үлчәүләре корып куячакбыз. Ул көнне һичкемгә нинди дә булса гаделсезлек кылынмас. Кылган эшләрегезнең гәрчич бөртеге кадәрлесен дә үлчәүгә салырбыз. Исәп-хисап ясау өчен Мин үзем дә җитәрмен»[18].**

**«Гамәленә күрә, һәркем төгәл әҗерен алыр. Аларның ни кылганнарын Аллаһ бик яхшы белә»[19].**

Аллаһы Тәгалә безне ул бөек көннең авырлыкларыннан һәм хәсрәтеннән коткарып, җәннәтләренә кертсен иде. Куркусыз һәм борчуларсыз колларыннан әйләсен!

---

17 «Зүмәра» сүрәсе, 39:69.

18 «Әнбия» сүрәсе, 21:47.

19 «Зүмәра» сүрәсе, 39:70.

www.darul-kutub.com

# Җәннәт һәм аның нигъмәтләре

*Сөекле кардәшем!*

Җәннәт өстен сыйфатларга иядер. Аның кимчелеге яки җитешсезлеге һич юктыр. Сахәбәләр пәйгамбәребездән җәннәт турында сораганнар.

«Аның чакма ташлары энҗе белән якуттан. Анда кергән – нигъмәткә ирешер. Анда өметсезлек юк, мәңгелек тормыш бар. Үлем юктыр, киемнәре чыланмас, яшьләр исә һич картаймас».

* * *

## Сарайлары һәм кунак йортлары

Мөэминнәр өчен анда мәһабәт сарайлар бар. Аллаһы Тәгалә болай дип боерган: **«Раббы газабыннан курыкканнар өчен берсе өстенә икенчесе корылган биналар булыр, асларыннан ермаклар агып тора торган зиннәтле урыннар хәзерләнгән. Болар – Аллаһ вәгъдә иткән нигъмәтләр. Ул беркайчан да вәгъдәсен бозмас»[20].**

[20] «Зүмәра» сүрәсе, 39:20.

www.darul-kutub.com

Ибне Кәсир рәхимәһуллаһ түбәндәгеләрне язган:

Аллаһы Тәгалә изге колларына хәбәр иткәнчә, «алар өчен бүлмәләр бар» дигән гыйбарәдә сарайларны күздә тота. Аерым бүлмәләр рәвешендә бер-берсе өстенә корылган гүзәл сарайларның бер ягыннан карасаң, икенче тарафы күренер.

Җәннәт сарайлары турында Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, болай дигән:

***«Бер кирпече алтыннан, бер кирпече көмештән, ә измәсе мускус һәм зәгъфраннандыр»[21].***

* * *

## Җәннәттәгеләрнең чатырлары

Җәннәттә чатырлар бардыр. Аллаһы Тәгалә бу хакта болай дигән:

**«Чатырлар эчендә кара күзле хур кызлары бар»[22].**

[21] Әхмәд ибне Хәнбәл, Тирмизи, Дарими.
[22] «Рахман» сүрәсе, 55:72.

www.darul-kutub.com

Җәннәттәге чатырлар энҗедән чигелгәндер һәм мәйданы аның 60 миль тәшкил итәдер. Чатырның бер читеннән икенче чите күренмәс. Ул мөэминнәр өчен әзерләнгән урын булыр.

* * *

## Җәннәтнең җимешләре һәм агачлары

Аллаһы Тәгалә анда йөзем, хөрмә, пальма һәм кедр агачлары булганлыгын хәбәр итә:

**«Тәкъва булган мөэминнәр өчен сәгадәттә кавышу булыр. Бакчалар, йөзем бөстаннары...»[23]**

**«Уңдагылар – бәхет ияләре, никадәр бәхетле булачак! Чәнечкесез, баллы чия агачлары, җимешләр белән каплаган банан агачларыннан төшкән күләгәләр, бетмәс-төкәнмәс асылмалы җимеш агачлары...»[24]**

* * *

23 «Нәба» сүрәсе, 78:31-32.

24 «Вакыйга» сүрәсе, 56:27-29.

www.darul-kutub.com

## Җәннәтнең кошлары һәм хайваннары

Анда бик тәмле итле кошлар һәм без белеп бетермәгән төрле-төрле хайваннар бар. Аллаһы Тәгалә җәннәттәгеләргә бирелгән нигъмәтләр турында болай дигән:

**«Аларга үзләре теләгән җимешләр, җаннары теләгән кош итләре бирелер»[25].**

Бер адәм пәйгамбәребезгә иярләнгән дөя китергән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, бу кешегә:

***«Синең өчен (җәннәттә) 700 дөя хәзерләнде»[26],*** – дигән.

* * *

## Җәннәттәгеләрнең елгалары һәм чишмәләре

Асларыннан елгалар аккан җәннәтләр бар икәнлекне Аллаһы Тәгалә хәбәр итә:

**«Сөендер иман китереп игелекле гамәл кылганнарны. Асларыннан чишмәләр**

[25] «Нәба» сүрәсе, 78:31-32.

[26] Мөслим.

www.darul-kutub.com

**агып торучы җәннәт бакчалары алар өчен әзерләнгән»[27].**

* * *

## Җәннәттәгеләрнең киемнәре

Җәннәткә керүчеләр киемнәрнең иң күркәмен киярләр. Бу киемнәр ефәктән һәм башка шундый иң яхшы тукымалардан тегелгән һәм дә алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән белән чигелгәндер:

**«Иман китереп, игелек кылганнарны асларыннан чишмәләр агып ятучы җәннәтләр кабул итәр. Алар анда алтын беләзекләр киеп, энҗеләр тагарлар. Киемнәре исә ефәктән тегелгән булыр»[28].**

* * *

## Аларның түшәкләре һәм кәнәфиләре

Җәннәт сарайларында, бакчаларында аларга рәхәт булсын өчен матур төсле тукымадан

27 «Бәкара» сүрәсе, 2:25.
28 «Хаҗ» сүрәсе, 22:23.

www.darulkutub.com

бизәп-бизәп эшләнгән тәхетләр һәм кәнәфиләр булачак.

**«Анда – затлы кәнәфиләр. Алларына касәләр куелыр. Кабартылган ястыклар тезелеп торыр. Анда гүзәл келәмнәр җәелгән булыр»[29].**

*** * ***

## Җәннәттәгеләрнең хезмәтчеләре

Җәннәттәгеләргә бик гүзәл һәм мөкәммәл яшь хезмәтчеләр бирелер:

**«Яннарында хезмәт өчен үлемсез яшь егетләр булыр. Кулларында мәңге корымас чишмәдән кувшиннар, касәләр, тустыганнарга тутырып алган эчемлек булыр...»[30]**

Аллаһы Тәгалә нинди нигъмәтләр хәзерләгән, ниндиләрен әле безгә белдермәгән... Кодси хәдистә әйтелгәнчә, аларны бер генә күз дә күрмәгән, бер генә колак та ишетмәгән, бер генә йөрәк тә кичермәгән.

**«Кылган гамәлләренә күрә бүләк буларак, нинди шатлык күрәчәкләрен, күпме әҗер**

29 «Гашия» сүрәсе, 88:13-16.

30 «Вакыйга» сүрәсе, 56:17-18.

www.darulkutub.com

**алачакларын бирәү дә белмәс»[31].**

*Сөекле мөселман кардәшем!*

Мондый хәлдә, хәзер үк җәннәткә керү билетын алыр өчен чарасын күр һәм берүк соңга калма!

* * *

[31] «Сәҗдә» сүрәсе, 32:17.

www.darul-kutub.com

# ҖӘННӘТКӘ КЕРҮ БИЛЕТЫ

Сәлман әл-Фарисидан шулар риваять ителде: Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, болай дип боерды: **«Җәннәткә керү бары тик: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим,» – гыйбарәсе белән рөхсәт ителер һәм җәннәттә бу кешенең кем улы һәм әтисе икәнлеге язылыр. Аны үзе биек, җимешләре җирдә булган җәннәтләргә кертерләр»[32].**

**«Тәкъва мөселманнар өчен җәннәт ерак булмас, якынайтылыр. Аллаһка юл тоткан һәр кешегә, Аллаһ куйган чикләрне һәм хөкемнәрне узмаганнарга, Үзен күрмәгән килеш тә, Раббының җәзасыннан курыккан адәмнәргә вә ихлас күңелле кешеләргә вәгъдә ителгән җәннәт менә шушы булыр. Анда иминлек илә керегез. Бу үлем янамаган мәңгелек көннәрнең башы булыр. Анда ни теләсәгез шул бар. Хозурыбызда тагын да мулрак»[33].**

---

[32] Әхмәт ибне Хәнбәл.

[33] «Каф» сүрәсе, 50:31-35.

www.darul-kutub.com

Җәнабы Хак бу аяти-кәримәләрдә җәннәткә керү паспортын шул 4 сыйфатны үзендә тәрбияләгән кешегә бирәчәген белдерә:

**Әүүәәб:** бары тик Аңа юнәлеп, газабыннан сакланган һәм рәхмәтен теләгән, Аңа эчкерсез булып тәүбә иткән;

**Хафиз:** Аллаһыга биргән сүзен һәрвакыт хәтерләгән, сүзен бозмаган һәм сүзеннән кайтмаган;

**Гайбән Аллаһыдан курыккан:** Аллаһыдан яшертен курыккан, ягъни Аллаһыны күрми торып та, Аның үзен күргәнлеген белеп һәм шуны истә тотып гыйбадәт кылган;

**Мүнииб:** Аллаһ янына бары тик Аның белән кавышу теләге булган йөрәк белән килүчегә.

Менә шушы 4 үзенчәлеге дә булган кешегә Җәнабы Хак бу аятьтә белдерелгәнчә, мөрәҗәгать итәр: *«Андый кешеләр өчен яныбызда әле тагын артыгы да булачак»*. Ә бу артыгы исә, Аллаһы Тәгаләнең рәхимлеген күрсәтә. Анда кергән һәркем Аллаһы Тәгаләнең җәмален, гүзәллеген күрәчәк. Аллаһы безнең үзенең җәмаленә каравыбызны теләр. Без дә Җәнабы Хактан гүзәллеген күрсәтүен сорыйбыз.

www.darul-kutub.com

*Мосафир туганым!*

Менә син шул рәвешле җәннәткә керү билетын алыр өчен кирәкле шартларны өйрәндең. Әгәр син боларны үтәмәсәң һәм билетыңны югалтсаң, ниләр булыр икән?

* * *

www.darul-kutub.com

# ҖӘННӘТТӘН МӘХРҮМ БУЛГАННАР

Аллаһ Тәгалә җәннәттән мәхрүм иткәннәргә килгәндә, аларның кемнәр икәнлеген белергә теләсәң, түбәндәрәк аларның үзенчәлекләрен күрсәтербез. Габдуллаһ ибне Гомәрдән (радыйаллаһу гәнһү) Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең түбәндәге сүзләре китерелгән: ***«Өч төркем бардыр ки, Җәнабы Хак аларга җәннәтне хәрам кылган:***

Эчкечелектә булганнар;

Буйсынмаучылар;

***Үз гаиләсен саткан (намусын саклый белмәгән) кешеләр»***[34]***.***

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу гәнһү) риваять ителгәнгә күрә, шул дүрт сыйныф кешеләрен җәннәткә кертмәү Аллаһы-ның хакыдыр:

1. Эчкечелектә булган;
2. Фаиз (процент) хисабына яшәгән;
3. Белә торып ятимнәр малын ашаган;
4. Ата-анасын санламаган.

---

[34] Әхмәд ибне Хәнбәл.

www.darul-kutub.com

Әбү Муса әл-Әшгаридән риваять ителгән:

«Җәннәткә шул өч сыйныфтан беркем дә керә алмас:

1. Эчкечелектә булган;

2. Туганнары белән арасын өзгән;

3. Сихер белән шөгыльләнгән кешеләр.

Кем тормышын эчкечелектә дәвам итсә, Аллаһы Тәгалә аңа Гаута елгасының суын эчерер.

*– Гаута нидер, йә Рәсүлуллаһ?*

*– Фахишәләрнең җенес әгъзаларыннан аккан судыр. Җәһәннәм әһеле аннан бик тә рәхәтсез булыр»*35.

Әбү Саиб ибне Зәйд (радыйаллаһу гәнһү) түбәндәгеләрне риваять иткән:

*«Бер мөселманның нәрсәне дә булса үлчәгәндә хәйлә куллануы – фаизларның иң начарыдыр. Һәм аларның туганнары каршында үз бурычлары бардыр. Болар Аллаһ тарафыннан кабул ителгәндер. Туганлык җепләрен өзгән кешегә Аллаһы Тәгалә җәннәткә керүне тыяр».*

Әбү Дауд Гукъбә ибне Әмирдән риваять ителгән: *«Мин Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләмнән, ишеттем:* ***«Ким итеп үлчәгән кеше җәннәткә керә алмас».***

[35] Әхмәд ибне Хәнбәл.

www.darul-kutub.com

*Әй, ахирәткә юл тоткан кардәшем!*

Сине яманлыклардан саклар өчен түбәндә язылган тәгълиматларны үтәвеңне сорыйбыз!

* * *

www.darul-kutub.com

# ҖӘҺӘННӘМ ҺӘМ АНЫҢ ГАЗАБЫ

Аллаһы Тәгалә Коръән-и Кәримдә һәм пәйгамбәребез аркылы безгә җәһәннәмне аңлаткан.

**«Ләкин – ни файда! Җәһәннәм – тәмуг уты, гөнаһлы кешене башыннан аягына кадәр ялмап алыр»[36].**

**«Син Сәкарнең ни икәнен беләсеңме? Сәкар – ул шундый тәмуг – берни калдырмый бөтенләй яндырып бетерә. Тиреләрне көйдерә»[37].**

Җәнабы Хак җәһәннәмнең исемен сорый һәм шуның белән безнең игътибарны җәлеп итә. Ягъни аларның итләрен, тиреләрен, нервларын, сөякләрен – һәрнәрсәсен ут йотачак һәм яңадан үз хәленә кайтарып, тагын яндыра башлаячак. Алар анда үлмәсләр дә, рәхәт яшәмәсләр дә.

Бу тема белән бәйле ике сахих хәдис:

Әбү Һүрайрадан (радыйаллаһу гәнһү) риваять ителгән:

---

[36] «Мәгариҗ» сүрәсе, 70:15-16.

[37] «Мүдәссир» сүрәсе, 74:27-29.

www.darulkutub.com

*– Менә сезнең яккан ут бар. Җәһәннәм аннан җитмеш кат эссерәктер.*

*– Әгәр дә шулай икән, ул һәрнәрсәне юк итәр – дип хәйран калдылар.*

*– Шунысы хак, аның уты 69 кат сүндерелгән. Ул дөньядагы барлык утларның кайнарлыгын үз эченә алган.*

## Җәһәннәмдәгеләрнең ризыклары

Зәкъкум агачы белән корыган чәнечкедер. Аятьтә әйтелгәнчә:

**«Шик юк ки, зәкъкум агачы – гөнаһка баткан кешенең ризыгыдыр. Эретелгән җиз кебек эчләрендә кайнап торачак»[38].**

**«Дари дигән чәнечкеле үсемлектән башка аларга һичбер ризык булмас...»[39]**

* * *

## Җәһәннәмдәгеләрнең эчемлекләре

Эретелгән металл белән тән пешергеч кайнар су.

---

[38] «Духан» сүрәсе, 44:43-46.

[39] «Гашия» сүрәсе, 88:6.

www.darulkutub.com

**«Әлбәттә, бер агачтан, зәкъкум агачыннан ашаячаксыз. Ашказаннарыгыз шуның агуы белән тулачак. Өстәвенә кайнап торган су эчәчәксез. Сусаган дөяләр ничек суга йотлыкса, сез дә шулай кибегерсез, кайнар су эчәргә мәҗбүр булырсыз»**[40].

**«Ярдәм сораганнарга эчәр өчен эрегән тимер сыман йөзне көйдереп ала торган су биреләчәк анда. Начар бер эчемлектер ул һәм алар ята торган урын да бик яман!»**[41]**.**

* * *

## Җәһәннәмдәгеләрнең агачлары һәм җимешләре

Аларның агачлары зәкъкум агачы булыр, ә җимешләре исә шайтан башы кебектер.

**«Ул агач җәһәннәмнең төбеннән үсеп чыгар. Ә аның җимешләре шайтан башына охшаган булыр»**[42]**.**

* * *

40 «Вакыйга» сүрәсе, 56: 52-55.

41 «Кәһеф» сүрәсе, 18:29.

42 «Саффат» сүрәсе, 37:64-65.

www.darul-kutub.com

## Җәһәннәмдәгеләрнең торачак җирләре

Җәннәткә капма-каршы, җәһәннәм аска таба катлам-катлам итеп ясалган. Иң астагы катламда – хәфизәналлаһ –монафикълар ятачак.

**«Монафикълар җәһәннәмнең иң аскы катында булачактыр. Аларга һичбер ярдәмче табылмас»[43].**

* * *

## Җәһәннәмдәгеләрнең киемнәре

«Хаҗ» һәм «Ибраһим» сүрәләрендә әйтелгәнчә, аларның киемнәре уттан һәм сумаладан булачак.

* * *

## Җәһәннәм әһелләре анда күпме калачак?

**«Озак вакытлар буена алар анда калачак»[44].**

43 «Ниса» сүрәсе, 4:145.

44 «Нәба» сүрәсе, 78:23.

www.darul-kutub.com

*Әй, ахирәткә юл тотучы мөселман кардәшем!*

Бөтен булган көчең белән уттан саклана күр! Яндырып-көйдереп алачак шул газапны исеңә төшер. Бик тә куркыныч булган зобаниларын, җәһәннәм сакчыларын онытма. Алар бик ачулы булып, кешеләрне мәсхәрәләп торырлар, ачулары йөзләренә бәреп чыгар. Аларның бар эшләре һәлак итүдән гыйбарәттер. Гөнаһ кылучыларга алар кап-кара сурәттә күренер. Җәһәннәм әһелләре елап, аларга ялварырлар:

«Әй, Малик! Бу тимер богаулар безгә бигрәк тә авыр килде, тиреләребез янып төште. Бетәрме икән бу газаплар? Зинһар, безне моннан чыгарсаң, гөнаһ юлына борылып та карамас идек!»

Бераздан соң аларга: «Сөйләшмәгез, йомыгыз авызыгызны! Сезнең өчен бары тик мәңгелек газап хәзерләнгән, ә моннан чыгу юлы юктыр», – диячәкләр.

Сез дөньяда вакытта исерек идегез. Нигә хәзер еларга?

Зина кылган вакытта, кайда иде күз яшьләрегез?

Азып-тузып йөргән чакта еладыгызмы?

www.darul-kutub.com

Хәйлә һәм тозак корганда кайгырдыгызмы?

Җәһәннәм сакчысы Малик аларга: «Сез монда калачаксыз», – дияр һәм шуны да өстәр:

**«Хактыр ки, Без сезгә дөреслек алып килдек. Ләкин күбегез шул дөреслекне сөймәс булды»[45].**

*Сөекле туганым!*

Мин синнән шуны сорарга телимен: «Синең тәнең җәһәннәм утына чыдарлыкмы? Үзәк өзгеч ул газапка никадәр түзәрсең син? Бу дөньядагы барлык уттан бик күп тапкыр кайнар булган ул җәһәннәм утыннан нигә сакланмыйсың син?!»

Утны без көндәлек тормышыбызда һәрдаим кулланабыз: ашарга пешерәбез, җылынабыз, дәваланабыз, шифа табабыз. Җир йөзендә кулланыла торган уттан файда бардыр, фәкать җәһәннәм утының, Аллаһ сакласын, бернинди шифасы юк һәм аңа чыдап булмыйдыр.

Моннан соңгы станциягә килеп эләкмәс өчен җәһәннәм утыннан саклый торган тәртипләрне аңлатып үтәрбез.

[45] «Зухруф» сүрәсе, 43:78.

www.darulkutub.com

# УТТАН ЕРАКЛАШТЫРГАН НӘРСӘЛӘР

*Сөекле туганым!*

Уттан ераклаштырган нәрсәләр шулардыр:

Әбү Һурайра (радыйаллаһу гәнһү) Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләмнән, риваять иткәнчә, күп дога кылу җәһәннәмнән ераклаштырыр.

Кем җәннәтне теләсә, җәннәт тә өч мәртәбә: «Аны җәннәткә кертә күр!» – дип үтенер. Кем җәһәннәмнән сакланырга теләсә, җәһәннәм: «Йә, Раббы! Аны уттан саклый күр!»– дип үзе дога кылыр.

Изге гамәлләр, ихлас һәм иман белән берлектә җәһәннәмнән ераклаштырып, җәннәткә китерәчәк.

Ике сахих хәдис-шәриф:

Әбү Сәгид әл-Худридан (радыйаллаһу гәнһү) хәбәр иткәнчә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

***«Кем Аллаһы ризалыгы өчен бер көн ураза тотса, Аллаһы Тәгалә аның йөзен җәһәннәмнән җитмеш фәрсах ераклаштырыр».***

www.darul-kutub.com

Әнәс ибне Мәлик (радыйаллаһу гәнһү) әйтүенчә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләм болай дигән:

***«Кем тиешле дәрәҗәдә таһәрәт алып мөселман кардәшенең янына килсә, ул кеше җәһәннәмнән җитмеш фәрсах ераклаштырылыр».***

**Яңадан да ике сахих хәдис:**

Гадий ибне Хатимнән (радыйаллаһу гәнһү) хәбәр ителгәнгә күрә, Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, болай дигән:

***«Сездән һәрберегез үзе белән җәһәннәм арасына бер хөрмә төше кадәр генә булса да пәрдә куйсын, бу аз булса да, бер гамәл булыр».***

Габдулла ибне Гомәр (радыйаллаһу гәнһү) әйтүенчә, Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, болай дигән:

***«Әгәр кемдер ачыккан мөселман кардәшен туйганчы ашатса һәм эчертсә, хәбәр ителде ки, Аллаһы аны киңлеге йөз еллык юлга тиң булган җитмеш чокыр ераклыкка җәһәннәмнән аерачак».***

www.darul-kutub.com

*Әй, ахирәткә юл тотучы кардәшем!*

Башка аять һәм хәдис китапларында бу темага карата тулырак мәгълүмат алырсыз.

Ә хәзер яңа перронга күч һәм көтеп тор!

* * *

www.darul-kutub.com

# НӘФЕСНЕҢ ХИСАПЛАРЫ

Һәр мөселман үзенең хәзергесен һәм киләчәген аңлы рәвештә анализлап карарга, хисап көне килгәнче, үз-үзенә хисап бирергә тиеш.

*Шулай итеп, мөселман кардәшем!*

Син үзеңне ничек итеп хисапка тартачаксың?

Җәнабы Хакның бәхетле юлына китерәчәк түбәндәге сорауларны үзеңә мөмкин кадәр ешрак бирергә тиешлесең:

1. Намазларыңны мәчеттә җәмәгать белән укыдыңмы?

2.Аллаһының китабыннан һәркөн ни дә булса укыдыңмы?

3. Үлем, кабер, ахирәт тормышы хакында берәр тапкыр булса да уйланганың булдымы?

4. Гөнаһлар кылгач, күз яшьләреңә буылып гафу, кичерү, истигъфар теләгәнең булдымы?

5. Аллаһыдан шәһитлек теләдеңме? Чөнки пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шуны әйткән:

«Кем Аллаһыдан (эчкерсез рәвештә) шәһадәт теләсә, урын-җирендә үлсә дә, шәһитләр

www.darul-kutub.com

мәртәбәсенә ирештереләчәктер».

6. Фәкыйрьләргә, мохтаҗларга ярдәм итә идеңме?

7. Бары тик Аллаһы өчен газап чигеп, үз нәфесең өчен газап чигүдән туктый алган идеңме?

8. Атаң белән анаңа игелек кылдыңмы?

9. Сиңа бер кайгы килгәндә, «Иннәә лилләһи үә иннәәә иләйһи рааҗигүүн» (без Аллаһыдан килдек һәм янә Аңа кайтачакбыз) дидеңме?

10. Йөрәгеңне нәфрәттән һәм тәкәббер булудан, дошманлык һәм көнчелектән чистарттыңмы?

11. Хезмәт хакы алуыңда һәм ашау-эчүеңдә Аллаһыдан курыктыңмы?

*Хөрмәтле мөселман кардәшем!*

Әгәр син әлеге сорауларны һәркөн исеңә төшереп төгәл җавап бирә алсаң, уңышка ирешүчеләрдән булырсың.

*Әй, ахирәт юлчысы!*

Ике җиһанда да бәхетле булсын өчен, киләсе перроннан ук  төшеп китмәс өчен, сиңа боларны хәзердән үк исеңә төшерәбез!

www.darul-kutub.com

# ШӘҺВӘТЕНӘ БИРЕЛГӘННӘРНЕҢ АХЫРЫ

Нәфес теләкләренә бирелүчеләр бу юлны дөрес дип саныйлар. Ләкин ул, дөнья һәм ахирәт тормышын куркыныч астына куйган кыска юлдыр.

Шәһвәт юлына басып, биш минутлык дөнья ләззәтләренә бирелгәннәрнең ахыры ачы нәтиҗәләргә китерәчәк.

Әнәс ибне Мәлик (радыйаллаһу гәнһү) хәбәр иткәнчә, Рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, түбәндәгеләрне сөйләгән:

***«Бу дөньяда вакытта күп нигъмәтләргә ирешкән бер кешедән җәһәннәмгә кергәч: «Дөньяда син берәр нигъмәт күрдеңме?» – дип сорарлар. Ул: «Юк, валлаһи, миңа дөньяда һичбер нигъмәт тимәде», – дип җавап бирәчәк.***

***Шулай ук бу дөньяда зур авырлыклар кичергән берәү җәннәткә кергәч, сорарлар: «Син дөньяда вакытта берәр төрле авырлык кичердеңме?» Ул адәм дә: «Мин дөньяда чакта һич авырлык күрмәдем», – дип җавап бирәчәк».***

www.darulkutub.com

Ахирәт көнендә онытылган кешенең бу дөньяда бер кыйммәте дә юктыр һәм киләчәктә аны җәза көтәдер.

Аннан соң ни булыр?

Нәфес корбанына әйләнеп, һәртөрле гөнаһ сазлыгына баткан, дөнья һәм ахирәт тормышын яман эшләргә алыштырган һәм шуның белән җаннарын гомер буе үкенеп хәсрәттә үткәрергә мәҗбүр булганнарның хәле никадәр кызганыч һәм гыйбрәттер. Бәхетне бары тик дөнья ләззәтләрендә табучыларның хәле бигрәк тә аянычтыр!

Бәхет чынлап та санап үтелгәннәрдә дип уйлаучылар ялгышмыйлармы икән?

Киләсе тукталышта шуларны карап үтәрбез.

* * *

www.darul-kutub.com

# Сәгадәт кайда?

*Әй, ахирәткә юл тотучы кардәшем!*

Күпләребез үз бәхетен эзли. Әсинең фикереңчә, кайда соң ул сәгадәт? Мал-мөлкәттәме? Нәселдә яисә гүзәллектәме? Кешеләрнең күбесе бәхетне җиңел генә, эшләмичә мал казану юлларында, интернетта, мода журналларында, ачык киенгән кызларда, күңел ачу һәм уен җирләрендә табарга тырыша. Ләкин алар һич кенә дә бәхетне анда таба алмаслар!

Җәнабы Хак боерган:

**«Кем минем кисәтүләремнән йөз чөерә, һичшиксез, аның тормышы газаплы булачак һәм Без аны Кыямәт көнендә дөм сукыр килеш кубарачакбыз»[46].**

Шулай булгач, бәхетне кайдан эзләргә? Аллаһы Тәгаләнең шул сүзенә дикъкать ит: **«Ир кешеме ул, хатынмы, мөселман булып, игелекле эшләр башкарса, аларны, һичшиксез матур тормышта яшәтәчәкбез. Һәм әҗерләрен дә кылган иң игелекле эшләре буенча бирербез»[47].**

[46] «Та-һа» сүрәсе, 20:124.

[47] «Нәхел» сүрәсе, 16:97.

www.darul-kutub.com

Дөнья һәм ахирәт бәхетенә бары тик Аллаһының әмерләрен һәм тыюларын икеләнүсез кабул итеп, төгәл үтәп барганда гына ирешергә мөмкиндер. Дөнья эшләренә артык бирелеп, сиңа ахирәт эшләрен начар итеп күрсәтергә теләгән, Аллаһының әмер һәм тыюларына каршы килгән берәүләрдән сакланырга киңәш итәм. Аларның сөйләгәннәре һәм биргән киңәшләре дөньяда бераз гына файда китерсәләр дә, ахирәттә мәңгелек интегү һәм газаптыр.

Бервакытны пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм бер җеназага катнашты, соңыннан нидер алып җиргә сипте һәм шулай диде:

***«Җәннәттә һәм җәһәннәмдә урыны язылмаган сездән беркем дә юктыр».*** «Алай булса, авырсынып, гамәлләрдән ераклаша күрмик тагын?» – дип сорагач, янә әйтте:

***«Сезнең өчен яратылган гамәлләрнең иң җиңелен сайлагыз. Кем сәгадәтне теләсә, яхшы кешеләрнең гамәлләрен бик тә җиңел башкарыр. Кем начар кешеләрдән булырга теләде исә, яман кешеләрнең эшләре аңа җиңелләштерелер».***

Ә соңыннан шул аяти-кәримәләрне укыды:

www.darul-kutub.com

**«Кемдер хәер-сәдака, зәкят бирер, кемдер гөнаһ кылудан, харамнан куркыр. Кемдер гүзәллеккә сокланыр һәм аның хаклыгын раслар. Без дә андыйларның Сәгадәткә барыр юлларын уң итәрбез. Әмма кем тар күңелле, матди һәм рухи саранлыкта булса, Аллаһка ихтыяҗ тоймаса, иң хәтәре – алдашса, ялганласа, гүзәллекне инкарь итсә, Без андыйларга иң хәтәр җәзага барыр юлларны уң итәрбез»**[48].

*Юлчы туганым!*

Инде бәхет эзләп, соңгы тукталышка килеп җиттең. Соңгы үтенечем буларак, васыятебезне тыңлап үтәргә киңәш итәм.

[48] «Ләйл» сүрәсе, 92:5-10.

www.darul-kutub.com

# БӨЕК ВАСЫЯТЬ

*Сөекле кардәшем!*

Хактыр ки, һәрбер кеше хәер казаныр өчен бу дөньяның күп кенә станцияләренә тукталырга мәҗбүрдер. Ә без исә синә пәйгамбәр әфәндебезнең: «Дин – ул нәсыйхәттер», – дигән сүзләрен искәртеп, дөньяда һәм ахирәттә синә күрсәтмә булачак әлеге сүзләр белән бәхәсне туктатырга телибез:

«Кайда гына булсаң да, тәкъва иясе бул. Һәр гөнаһ гамәлдән соң бер игелек кыл, ул гөнаһыңны юсын. ***Тирә-юньдәгеләргә карата шәфкатьлелек күрсәт».***

Аллаһым, юмартлыгың һәм рәхимлегең белән безне тәкъва иясе булган колларыңнан итә күр! Амин.

* * *

www.darul-kutub.com

# СОҢГЫ СҮЗ

*Әй, ахирәткә юл тотучы туганым!*

Сиңа ахирәт юлында көткән авырлыкларны һәм барлык куркуларыңны җиңәргә ярдәм итәчәк төп шартларны тәкъдим иттек. Әгәр аларны сөенеп һәм арттырып үти алсаң, котылганнар арасында булырсың. Укып һәм өйрәнеп, башыңа киләчәкләрне алдан белеп торсаң, хәсрәт күрмәссең һәм хисабыңны да җиңел генә тапшырырсың. Бу сәяхәтеңдә Аллаһының һәм рәсүленең әмер һәм теләкләрен төгәл итеп үтәргә киңәш итәм.

Аллаһы Тәгалә безне һәм сезне җәннәтләренә кертсен, җәһәннәмнән азат итсен иде! Амин.

Пәйгамбәр әфәндебезгә, аның гаиләсенә һәм әсхабына бик күп сәламнәр булсын. Барлык хәмед-мактаулар Раббыбызга махсустыр.

* * *

www.darul-kutub.com

## Васыять хакында

Ибне Гомәр, радыйаллаһу гәнһү шуларны аңлата: *«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләм, боерды:* ***«Әгәр мөселманның васыять итеп калдырырлык милке булып та, васыятьнамә язмаса, аның бу милеккә ия булган хәлдә ике көннән артык яшәве хаксызлыктыр»[49].***

* * *

## Васыять һәм инфакъ вакыты

Әбү Һүрайра, радыйаллаһу гәнһү, аңлата:

«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи үә сәлләмнән: «Садаканың кайсысы өстенрәк?» – дип соралды.

***«Сау-сәламәт вакытыңда фәкыйрь булудан куркып, бай булуга өмет иткән чагыңда, малга карата саран була торып та садака бирүеңдер»*** – диде, аннан соң дәвам итте: ***«Шул рәвешле садака бирүеңне җаның бугазыңа җиткәнче дәвам ит. Соңгы сулышың якынай-***

---

49 Бохари һәм Мөслим.

www.darul-kutub.com

***гач бирелгән садакадан файда юктыр, чөнки малың инде башкаларга күчкән булыр»*****[50].**

* * *

## Һәркем васыятен хәзерләргә тиеш

Һәр мөселман соңгы сулышына кадәр васыятен язарга тиеш. Васыятьне үлем хасталыгы вакытында язу важиб, сәламәт чагында язып, үз янында йөртү мөстәхәб, ягъни, мәҗбүри булмаса да, яхшы эш дип санала.

Васыятеңдә балаларыңа, якыннарыңа соңгы нәсыйхәтеңне бирергә тиешсең. Әгәр өстеңдә якыннарыңның хаклары һәм бирәчәк бурычларың булса, аларның бирелүен таләп ит, үтәлмәгән хаҗ бурычың калса, синең өчен анда вәкил җибәрүләрен сора. Җеназаң һәм җирләү хакында күрсәтмәләреңне калдыр. Бу теләкләрнең үтәлүе өчен ике гадел шаһит янында бер якыныңа опекунлык вазифасы йөкләнсен.

[50] Бохари.

www.darul-kutub.com

## Васыять калдырмыйча үлгәннәргә сөйләшү хакы бирелмәс

Үлгән мөэминнәрнең рухлары бер-берсе белән күрешерләр, бигрәк тә җомга көн кичләрендә үзара сөйләшерләр. Үлгән кешенең рухы күкләргә күтәрелгәч, мөэминнәрнең рухлары килеп, дөньядагы танышлары турында сорашырлар. Васыять итмичә үлгәннәрнең рухларына сөйләшү хакы бирелмәс .

* * *

www.darul-kutub.com

# ДИНИ ВАСЫЯТЬНАМӘ

## Васыять һәм аның әһәмияте хакында кайбер фикерләр

Васыять – үлем якынлашкан чагында үзебез эшләргә теләп тә, өлгерми калган эшләребезнең үтәлүен яшәп калган якыннарыбыздан үтенү, икенче төрле әйткәндә, сау-сәламәт чагында тулысынча үти алмаган вазифаларыбызның үтәлүен теләп калдыру була.

Без мирас итеп калдырган малның өчтән бер өлеше белән, өстебездә булган кеше һәм Аллаһы хакларының үтәлергә мөмкин кадәрен түләүне васыять итү – важиб булып санала. Бу васыятьнең үтәлешен тәэмин итү варисларыбыз өчен важибтыр.

Кеше үз кулында малы була торып та, үзе сәламәт вакытта башкарырга форсат чыкмаган бурычларының үтәлүен васыять итә ала. Ләкин бер шарт белән: аларны башкару өчен җитәрлек мал калдырырга тиеш. Мәсәлән, зәкят, тотылмаган ураза яки башкарылмаган хаҗ, фидия бурычы кебек матди бурычларны үтәү өчен җитәрлек дәрәҗәдә мал калдырган очракта, моның хакында васыять калдыру важиб була.

www.darul-kutub.com

# ВАСЫЯТЬНАМӘ ҮРНӘГЕ

Мин, бу юлларның астында имзасы булган васыять итүче буларак:

Аллаһыдан башка илаһ булмаганлыкка, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның колы һәм рәсүле булганлыгына, кыямәт көненең төгәл буларак һәм шик-шөбһәгә урын калдырмый торган рәвештә киләчәгенә, бөек Аллаһының кабердәгеләрне яңадан терелтәчәгенә шаһитлек итәм һәм шуларны әйтәмен:

Гаиләмнән һәм нәселемнән үземнән соң калганнарга васыятем шулдыр:

Аллаһыдан куркып яшәгез, Аның әмерләрен һәм тыйганнарын игътибар белән һәм төп-төгәл үтәгез, аралары бозылган кешеләрне татулаштырыгыз, Аллаһыга һәм рәсүленә итагать итегез.

Ибраһим һәм Ягъкуб пәйгамбәрләр үз улларына васыять һәм киңәш иткән кебек, мин дә сезгә хәзер васыять итәмен. Алар үз улларына болай дигәннәр:

Ибраһим белән Ягъкуб галәйһиссәләм моны балаларына васыять итеп калдырды. Хәзрәти

www.darul-kutub.com

Ягъкуб әйтте: **«Угылларым, хактыр ки, сезнең өчен бу динне Аллаһ сайлап бирде, шуңа күрә, бары тик мөселман булып яшәгез, мөселман булып үлегез»[51].**

1. Сезгә Аллаһының әмерләренә бәйле булып һәм Аның тыйганнарыннан ерак торып, тәкъвалы тормыш кичерүегезне васыять һәм киңәш итәм. Авырган чакларыгызда һәм үлем каршысында сезгә сабыр булырга, минем хакта бары тик яхшы сүзләр сөйләргә, минем өчен Аллаһыдан бик күп гафу һәм истигъфар теләргә, догалар кылырга, Раббымның мине җәннәтенә куеп, җәһәннәм утыннан ерак кылуын теләргә васыять итәм.

2. Әгәр дә мине үлем алса һәм минем рухым Яралтучыма менеп җиткәнче, сез моны укый алсагыз, ул тәкъдирдә, үзегез хәбәр бирә алган игелекле кешеләрне яныма чакыруыгызны һәм алар тарафыннан миңа шәһадәт кәлимәсенең кабатлап әйтелүен соравыгызны васыять итәм.

3. Вафат булгач, күзләремне йомдырып, уң ягыма яткырырга, йөземне кыйблага каратып куярга киңәш һәм васыять итәм.

[51] «Бәкара» сүрәсе, 2:132.

www.darul-kutub.com

4. Мин үлгәч, җеназамны кешеләрне көттермичә, тиз арада хәзерләвегезне, якын-ерак барча туганнарга: мине таныганнарга һәм бигрәк тә игелекле кешеләргә хәбәр итүегезне теләп васыять итәм. Мәетемне юучылар хәзерлекле булсыннар, җеназа намазымны тиз кылсыннар, мине соңгы юлга озату һәм җирләү эшләрен ашыгыч рәвештә башкарсыннар.

5. Сезгә аерым васыятем: мәетемне юачак кешеләр ышанычлы һәм тәртипле кешеләрдән булсыннар, мине яхшы юсыннар. Эшләрен «Аллаһ ризалыгы өчен» дип башласыннар. Әгәр юган чакта нинди дә булса яхшы ягымны күрсәләр – хозурлансыннар, инде начарлыгымны күрәләр икән – яшерсеннәр. Мине юып бетергәч, тәнемне чиста коры тукыма белән сөртеп киптерсеннәр һәм өстемә хуш исле берәр нәрсә сөртсеннәр. Нигездә, мәетемне юучыларга карата үтенечем шулдыр.

6. Сезгә васыятем: өч кисәктән торган, ак һәм чиста бер тукыма белән бар тәнемне төреп кәфенләсеннәр. Кәфенемнең өч аерым кисәктән торуын һәм хуш исле булуын телимен.

7. Минем җеназа намазымны кылучылар аны бер фарыз намаз артыннан кылсыннар. Җеназа

www.darul-kutub.com

намазымда сафлар саны өчтән дә аз булмасын дип игътибарлык күрсәтсеннәр.

8. Җеназа намазымда догаларны һәм Коръән аятьләрен кирәгеннән артык югары тавыш белән укымасыннар. Җеназамны артык сузмасыннар, килешмәгән һәм кирәксез эшләргә урын калдырмасыннар.

9. Китап белән сөннәткә каршы килгән һәртөрле эш һәм хәрәкәтнең: кычкырып елауларның, өс-баш, кием ертуларның һәм йөзен тырмауларның җеназамда күзәтелүеннән мин бик ерак торамын. Моңа аеруча дикъкать ителсен!

10. Минем сезгә киңәшем: әгәр дә мөмкин булса, каберемне бераз тирән итеп казыгыз. Мине кабергә уң ягым белән куйсыннар. Йөземне кыйбла тарафына юнәлтсеннәр. Кабергә иңдергән кеше әлеге доганы кылсын: «Бисмилләһи үә гәләә сүннәти Расүүлилләһи», ягъни, «Аллаһның исеме һәм рәсүленең сөннәте белән сине монда иңдерәм». Җеназама катнашып, мине каберемә тикле озатып килгәннәрнең һәрберсе өчәр уч туфрак алып, баш очыма сипсеннәр.

www.darul-kutub.com

11. Сезгә васыятем шулдыр: минем каберем өстенә бернәрсә дә кормагыз. Каберемнең өстендә кемнең дә булса утыруы яки йөрүе бер генә дә ярый торган эш түгел, хәләл булмас.

12. Сезгә тагын бер васыятем бар: каберемне табыну урыны хәленә китермәгез, өстенә нинди дә булса корылма төземәгез, артык биекләтмәгез. Ирләр минем каберемә каравылда торган кебек чиратлашып килергә тырышмасыннар. Хатыннар исә ярамаган кыяфәттә каберемә һич килмәсеннәр.

13. Сезгә шуны васыять итәм: мине кабергә җирләгәннән соң, минем өчен күп тапкыр Аллаһыдан гафу теләгез, истигъфарда булыгыз.

14. Тагын бер васыятем: мине искә алу теләге белән яки шуңа охшаш максат белән беркем дә кеше җыймасын, тантана уздырмасын. Бернинди дә тантана яки мәҗлес кирәк түгел, җеназа вакытында әйтелгән сүзләр, кайгы уртаклашу җитәрлек. Янәдән искә төшереп үтәмен: сак булыгыз, мине искә алу теләге белән һәр ел саен кабат-кабат мәҗлесләр уздырырга тырышмагыз.

15. Якыннарымнан булган кешеләрнең минем үлемем сәбәпле, өч көннән артык матәм тотулары килешмәс. Бары тик хатыным гына минем

www.darul-kutub.com

өчен дүрт ай дәвамында матәм тота, чөнки бу аятьтә күрсәтелгән. Әгәр минем хатыным йөкле булса, ул тәкъдирдә аның гыйддәте, ягъни көтү вакыты, баласын тудырганчы дәвам итә.

16. Сезгә аеруча киңәш итәм: (мәет чыккан өйдә) аш хәзерләп, кайгыгызны уртаклашыр өчен килгәннәрне сыйламагыз.

17. Балаларыма һәм башкаларга васыятем: мин түбәндәрәк яздырган мәсьәләләргә игътибарлы булсыннар, барлык санап үткәннәремне төгәл башкарсыннар. (Шул ук вакытта, үтәргә җитешми калганнарын хәтерләреннән чыгармасыннар иде. Боларны эшләгәнче үлеп киткән очракта, бу бүлемнәргә аеруча игътибарлы булсыннар һәм алдан ук кайгыртсыннар иде). Һәм сезгә шуны да әйтергә телимен: мин фәлән җирдәге фәләнчә адреслы йортымны вакуф карамагына биргән идем. Шулай ук фәлән суммага банк чегын/чекларын да лаеклы фәкыйрьләргә һәм мохтаҗ кешеләргә ярдәм өчен вакуф малы итеп калдырам. Яисә боларны үз нәселемнән булганнарга гаилә вакуфы итегез.

18. Сезгә тагын бер васыятем шулдыр: үземнән соң калдырган мирас акчасыннан шулкадәрлесенең укыту оешмаларына, Коръән

уку курсларына, хафизлыкка өйрәнүчеләргә һәм башка шундый кешеләргә сәдака итеп бирелүен телимен. Ләкин бу сумма калдырылган мирасның өчтән береннән артмаска тиеш.

Монда иң мөһим һәм урынлы булганы, калдырылган мирастан васыять итүченең якыннары арасында фәкыйрь һәм мохтаҗ кешеләр булса, һәм мираста аларның өлешләре булмаса, садакаларның шуларга бирелүе дөрестер. Бу кешеләрнең исемнәре түбәндәгеләр: (______________)

19. Сезгә башка бер васыятем: өстемдә булган бурычларымны мөмкин кадәр тизрәк түләгез. Бурычларым шул чират буенча түләнсен: Шуның кадәр сум акча фәлән кешегә, яшәү адресы мондый, шушы кадәресе фәләнгә, адресы будыр. Безнең арабызда килешү кәгазе бар/юк. (Шул рәвешле, васыять язучы бөтен булган бурычларын һәм аларны алачак кешеләрнең исемнәрен һәм адресларын язып куярга тиеш).

20. Сезгә тагын бер васыятем шулдыр: исемнәре һәм адреслары түбәндә күрсәтелгән кешеләрнең миңа бирәчәк бурычлары бар. Бурыч кәгазьләре нигезендә, бу кешеләрдән бурычларының алынуын телим. Фәлән кешедән

www.darul-kutub.com

алачагым шулкадәр, шул адрес буенча яши. (Шул рәвешле, аңа бирәчәк бурычлары булган барлык кешеләрнең исемнәрен һәм адресларын язып чыга, бурыч кәгазьләренең булу-булмавын да күрсәтә).

21. Бөтен балаларыма һәм якыннарыма иң мөһим васыятем шулдыр:

Намазларын һичбер вакыт ташламасыннар, дөрес итеп укуларын дәвам иттерсеннәр.

Уразаларын тотып, зәкятләрен тулысынча түләсеннәр.

Миннән соң бер-берләреннән аерылмасыннар.

Улларыма аерым васыятем: кыз туганнары белән яхшы мөгамәләдә булсыннар, хәтта алар кияүгә чыкканнан соң да кайгыртучанлык күрсәтсеннәр. Сезгә шуны белдерәмен һәм бөек Аллаһны шаһит итеп аламын: минем өстә хакы булган һәркемгә дә яхшы мөнәсәбәт күрсәтергә тырыштым, беркемгә дә авырлык китерергә теләмәдем. Минем соңгы теләгем: алар да миңа карата яхшы мөнәсәбәттә булсыннар, кичерсеннәр, кече күңеллелек күрсәтсеннәр иде.

22. Ниһаять, гаиләмә, улларыма һәм кызларыма васыятем шул булыр:

www.darul-kutub.com

Сабырлык күрсәтсеннәр. Мин үлде дип, Аллаһының тәкъдиренә каршы ризасызлык белдермәсеннәр. Минем васыятем шушылардан гыйбарәт булып, шул илаһи хәбәр белән аны тәмамлыймын:

**«Васыятьне ишеткәч һәм кабул иткәннән соң, бу васыятьне үзгәрткән кешеләр гөнаһлы булыр. Шик юк ки, Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора»**[52].

Бу васыять ............. шәһәрендә ............. көндә язылды.

**Васыять итүче/имза**

...........................................................

**Шаһитләр/имза**

.................................................................

Бу васыятьнамә түбәндәгечә тормышка ашырылды:

Дата: .........../............../...................

52 «Бәкара» сүрәсе, 2:181.

www.darul-kutub.com

# ВАСЫЯТЬ КАЛДЫРМЫЙЧА ҮЛГӘННӘР

Әбү Шейх ибне Хиббан «Васыятьләр» исемле китабында Кайс ибне Кабисәдән (р.г.) шуны риваять иткән:

«Васыять итмичә үлеп киткән кеше, башка үлеләр белән сөйләшә алмас».

Бервакыт, пәйгамбәребездән сорадылар:

– Йә, Рәсүлүллаһ, үлеләр сөйләшә алырмы?

– Әйе, алар бер-берсенә йөрешерләр, – дип җавап бирде Рәсүлебез.

Ибн Аби әд-Дунья, Сәгид ибне Халид аркылы Ибн Зәйд әл-Әнсаридан (р.г.) Басралы бер кешенең сүзләрен хәбәр иткән.

«Мин кабер казучы идем. Беркөнне кабер казыган вакытта, башымны аңа якын куеп яттым. Төшемә ике хатын-кыз керде. Аларның берсе:

– Йә, Габдуллаһ! Аллаһы хакы өчен бу хатынны безгә күрше итмә! – диде.

Мин куркуымнан уяндым. Карасам, яныма бер хатын мәете китерелгән. Шулвакыт: «Артыгызда башка бер буш кабер бар, шунда күмегез» – дип, аларны үзем казыган кабердән җибәрдем.

www.darul-kutub.com

Төнлә белән янәдән шул ике хатынны төшемдә күрдем. Ул хатын миңа дәште:

– Аллаһы сиңа әҗер-савабын бирсен, бездән бик зур яманлыкны ераклаштырдың!

– Нигә синең күршең бер дә сөйләшми? – дип сорадым.

– Минем иптәшем васыять калдырмыйча үлде. Васыять итмичә үлгәннәрнең җәзасы – кыяматкә кадәр сөйләшмәүдер, дип җавап бирде.

Әнәс, радыйаллаһу гәнһүдән, Дәйләми риваять иткәнчә, рәсүлүллаһ, салләллаһу галәйһи үә сәлләм, түбәндәгеләрне әйткән:

«Җәннәт әһеленнән ике хатынны күрдем. Берсе сөйләшә, икенчесе сөйләшә алмый иде. Мин: ***«Син нигә сөйләшәсең, ә теге хатын сөйләшә алмый?»*** – дидем. Хатын әйтте: «Мин васыятемне калдырдым, ә бу хатын исә, васыять итмичә үлде. Инде кыяматкә кадәр сөйләшә алмаячак».

* * *

www.darul-kutub.com

# КУШЫМТА 2

# АХИРӘТ ҺАВА ЮЛЛАРЫ

Дөнья – Ахирәт самолетының чартерлы рейсы буенча очыш программасы:

Баш пилот: **Газраил**
Рейсның башлангыч ноктасы: **Дөнья**
Очыш сәгате: **Әҗәл вакыты**
Төшү урыны: **Кабер**
Бару ноктасы: **Җәннәт яки җәһәннәм**

Юлчының белешмәсе:
Исеме: **Кеше**
Вазифасы: **Коллык**
Ясалган матдәсе: **Туфрак**

**БАГАЖ:**
Берничә метр тукыма.
Игелекле гамәлләр.
Игелекле баласының догасы.
Файдалы гыйлем.

www.darul-kutub.com

*Искәрмә:* башка нәрсәләр алырга катгый тыелган.

Билет алыштыру: Билетыгызны алыштыру мөмкин түгел, бары тик садака биреп вакытын кичектерергә була.

* * *

www.darul-kutub.com

# СӘЯХӘТ КҮҢЕЛЛЕ УЗСЫН ӨЧЕН

Сәяхәтегезне исән-имин уздырыр өчен Коръәни Кәримдә һәм хәдис-шәрифләрдә бирелгән тәгълиматларны үтәп баруыгызны сорыйбыз.

**Мөһим хәбәр:**

Аллаһы һәм рәсүленә берсүзсез итагать итү.

Үлемне һәрвакыт истә тоту.

Ахирәттә безне җәннәт яки җәһәннәм көтәчәген белеп тору.

Ата белән анага игелек кылу.

Ашау-эчүнең һәрвакыт хәләл булуы.

* * *

www.darul-kutub.com

# МӨҺИМ ИСКӘРТҮ

Паспортыгыз (гамәл дәфтәрегез) тикшереләчәк!

Тикшерү барышында, билгеле бер вазифалар йөкләнгән фәрештәләр, кешенең яшәлгән гомеренә бәя бирерләр. Әгәр дә визалар үз вакытында эшләнгән булса (намаз, ураза, зәкят һ.б.), иншә Аллаһ, җәннәткә барып ирешерсез.

Паспорт контроле белән бәйле булган шул сорауларга җавапларны хәзердән үк әзерләп куярга кирәк:

Гомереңне кайда үткәрдең?

Яшьлегеңне ничек үткәрдең?

Малыңны ничек таптың?

Малыңны кайда сарыф иттең?

Аллаһы юлында ниләр эшләдең?

Искәрмә: Хөрмәтле юлчылар! Тулырак мәгълүмат алырга теләүчеләрне Коръәни Кәримгә һәм пәйгамбәребезнең хәдис-шәрифләренә мөрәҗәгать итәргә чакырабыз.

Аллаһы Тәгалә иң соңгы сәяхәтебезне җәннәттә тәмамлауны һәммәбезгә дә насыйп әйләсен. Амин.

www.darul-kutub.com

# НАМАЗ (АХИРӘТ БИЛЕТЫ)

Намаз – диннең терәге, мөэминнең мигъраҗыдыр,

Намаз – чирле рухларның тәэсирле дәвасыдыр.

Намаз кылган коткарыр тайпылудан үз динен.

Намаз кылмаган табар тик җәһәннәмдә үзен.

Начар-яман эшләрдән саклыйдыр безне намаз,

Начар эшләрне ташлаткан, гөнаһтан коткарган да намаз.

Намаз – нурдыр, яктылыктыр кеше күңелендә.

Намаз – җавап булачактыр Мүнкәр белән Нәкиргә.

Намаз – салкын күләгәдер, кыямәт кайнарында.

Намаз калкан кебектер, җәһәннәм ялкынында.

Намаздыр бер-берсенә бәйләгән мөэминнәрне,

Намаздыр дуслаштырган үпкәле кешеләрне.

Намаз кылган һәрвакыт яхшы гамәлләр эшләр.

Намазда хозур, рәхәтлек таба алыр кешеләр.

Намаз – ахирәт билеты, ансыз юлга чыгылмас.

Билетсыз юлга чыкканның йөзенә һич каралмас.

www.darul-kutub.com

# ЭЧТӘЛЕК

Тәкъдим.........................................4
Кереш. Ахирәт паспортыбыз хәзерме?.........7
Дөньядан кире кайту чарасы: үлем...................12
Кереш сүзе..................................................14
Багаж.............................................16
Кая кире кайтабыз?........................................18
Юлга чыгу вакыты якынлашты......................20
Иң зур имтихан..............................................22
Сыйрат.........................................................25
Мөэминнәрнең сыйрат күперендәге хәле.....27
Монафикъларның сыйрат күперендәге хәле.....29
Бөек тупланыш..............................................31
Җәннәт һәм аның нигъмәтләре........................33
Сарайлары һәм кунак йортлары.......................33
Җәннәттәгеләрнең чатырлары.......................34
Җәннәтнең җимешләре һәм агачлары..........35
Җәннәтнең кошлары һәм хайваннары.........36
Җәннәттәгеләрнең елгалары һәм чишмәләре...36

Җәннәттәгеләрнең киемнәре..........................37
Аларның түшәкләре һәм ятаклары...............37
Җәннәттәгеләрнең хезмәтчеләре...................38
Җәннәткә керү билеты...................................40
Җәннәттән мәхрүм булганнар.......................43
Җәһәннәм һәм аның газабы........................46
Җәһәннәмдәгеләрнең ризыгы........................47
Җәһәннәмдәгеләрнең агачлары һәм
җимешләре.....................................................47
Җәһәннәмдәгеләрнең торачак җирләре........48
Җәһәннәмдәгеләрнең киеме.........................49
Җәһәннәм әһеле анда күпме калачак?.......... 49
Уттан ераклаштырган нәрсәләр....................52
Нәфеснең хисаплары.......................................55
Шәһвәтенә бирелгәннәрнең ахыры..............57
Сәгадәт кайда?................................................59
Бөек васыять...................................................62
Соңгы сүз....................................................... 63
Васыять хакында........................................... 64
Васыять һәм инфакъ вакыты.......................64

Һәркем үз васыятен хәзерләргә тиеш..........64
Васыять итмичә үлгәннәргә сүз хакы
бирелмәс........................................................66
Дини васыятьнамә............................................67
Васыятьнамә үрнәге.........................................68
Васыять итмичә үлгәннәр.................................77
Ахирәт һава юллары........................................79
Бәхетле сәяхәт өчен.........................................81
Мөһим кисәтү...................................................82
Намаз (ахирәт билеты)....................................83

www.darul-kutub.com

*Искәрмәләр өчен*

www.darul-kutub.com

Мәңгелеккә юл тотучының
**АХИРӘТ ПАСПОРТЫ.** – Казан:
Хузур-Спокойствие, 2014. – 88 бит.

*Книга предназначена для имамов, муэдзинов, преподвателей воскресных курсов при мечетях, а также для широкого круга читателей.*

По вопросам оптовых закупок этой книги и других изданий обращаться по телефону: (843) 202-07-74 и по адресам: ул. Газовая, д. 19 (зд. Российского исламского института); ул. Лобачевского д. 6 (зд. ДУМ РТ).
Сайт издательского дома «Хузур» Huzur.ru

**Одобрено к печати решением № 14-028 Экспертного совета ЦРО-ДУМ РТ**

*© Издательство «Хузур-Спокойствие», 1435/2014*

Формат 84x108 1/32, печатных листов: 2,5;
бумага офсетная, печать офсетная, тираж 5000 экз.
г. Казань, пр. Победы, 30, тел.: 251 47 88,
электронная почта: ipk_ppk@mail.ru

Типография «Астор и Я», г. Казань, ул. Ахтямова, д.13а. Отпечатано в соответствии с предоставленным электронным материалом.

www.darulkutub.com